РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 14 марты 16нчы номерлы**

Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә кулланучга тапшыру өчен һәм (яки)куллану өчен билгеләнгән, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль милек исемлеген раслау турында» 38 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлеше, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә кулланучга тапшыру өчен һәм (яки)куллану өчен билгеләнгән, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль милек исемлекләрен раслау турында» 38 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гаммәви мәгълүмат чараларында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин